РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**

**сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**ИСКЕ КАЗИЛЕ**

**авыл җирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27 ноябрь 2020 ел** **№ 13**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Атабай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Атабай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2020 елнын 8 нче декабренэ билгеләргә:

1.1. Халык жыенын уткэру вакыты - 2020 елнын 8 декабрендэ 11.00 сэгатьтэн 12.00 сэгатькэ кадэр.

1.2. Уткэру урыны-Атабай авылы, Узэк урамы, 14 нче йорт, авыл клубы бинасы янында.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Атабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2021 елда 2400 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1) Атабай т. п. да Үзәк урамы хэм Купер урамы буенча юл-урам челтәрен төзеклэндерү (вак таш сатып алу, ташу,  җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2) Атабай т. п. юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Атабай т.п. территориясен чуп улэннэреннэн чистарту (чапкыч очен запас частлэр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
4) Атабай т. п. да янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
5) Атабай т. п. зираты территориясен төзекләндерү (бункер сатып алу һәм урнаштыру, мәйданчык булдыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, материаллар сатып алу)

« ӘЙЕ»                                        «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________И.Х.Сәгдиев